Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

1 ноябрь 2019 ел N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге Тайсуган авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылында Ленин, Чишмә, Сәләхетдинов урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылында Тукай, Инеш урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 16 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылында Вахитов, Зәй, Яшьләр урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: вак ташлы юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыены этапларын Тайсуган авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Тайсуган авылы, Ленин урамы, 19 нчы йортта уздырырга.
6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

7. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Тайсуган авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Тайсуган авыл җирлеге
башлыгы урынбасары И.И. Яруллин